**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Урюм авыл җирлегенең Урюм торак пунктында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

**02 октябрь, 2020 ел** **№ 1**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 56, 25.1 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, “Сез, 2020 елга җыелган 204325 (ике йөз дүрт мең өч йөз егерме биш) сум күләмендәге гражданнарның үзара салым акчаларын “Урюм авылы эчендәге урамнарны ремонтлау өчен вак таш сатып алу" дан “Урюм авылының Чапаев һәм Пушкин урамнарын ремонтлау өчен ком сатып алу һәм тиешле техника яллау”га күчерергә ризамы?”сораулары буенча 2020 елның 2 октябрендә булган гражданнар җыены нәтиҗәләрен кертеп, гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә, сайлау хокукына ия булган 341 җыенда катнашучы кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыены катнашучылары саны – 173 кеше.

Гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары, тавыш бирү нәтиҗәләре буенча, киләсе рәвештә исәпләнде:

“Риза” позициясе өчен гражданнар җыенының 173 катнашучысы тавыш бирде;

“Каршы” позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар кылды:

1. 1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Урюм авыл җирлегенең Урюм торак пунктында узган гражданнар җыенын булып узган дип, ә җыен нәтиҗәләрен чын дип тану.

2. “Сез, 2020 елга җыелган 204325 (ике йөз дүрт мең өч йөз егерме биш) сум күләмендәге гражданнарның үзара салым акчаларын “Урюм авылы эчендәге урамнарны ремонтлау өчен вак таш сатып алу" дан “Урюм авылының Чапаев һәм Пушкин урамнарын ремонтлау өчен ком сатып алу һәм тиешле техника яллау”га күчерергә ризамы?” сораулары буенча кабул ителгән карарны чын дип тану

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен, халыкка җиткерү максатыннан, мәгълүмати стендларда, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы”нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) беркетергә.

4. Әлеге карарны, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына юнәлтергә.

**Гражданнар җыенында**
**рәислек итүче** **Н.М. Краснов**

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Урюм авыл җирлеге**
**башлыгы** **Н.М. Краснов**